**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«26» сентябрь 2022 ел №408

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 29 окябренә 10.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авылында Үзәк урамы буенча 4А йорт Кече Шилнә авылының Гагарина ур., Ленина ур., К.Маркса ур., Үзәк ур., Шоколадная ур., Дубовая Грива ур., А.Цыганова ур., Московская ур., Кирова ур., Даричева ур., Митрофанова ур., Магистральная ур., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 29 окябренә 11.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авылында Вишневая урамы буенча 9 йорт янында Кече Шилнә авылының Водопроводная ур., Дальняя ур., Цветочная ур., Солнечная ур., Родниковая ур., Новая ур., Набережная ур., Восточная ур., Татарстан ур., Молодежная ур., Советская ур., Садовая ур., Луговая ур., Подгорная ур., Полевая ур., Поселковая ур., Вишневая ур., Строительная ур., Студенческая ур., Корабельная ур., Радужная ур., Парковая ур., Тенистая ур., Нижняя ур., Радостная ур., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 29 окябренә 12.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авылында Удачная урамы буенча 18 йорт янында Кече Шилнә авылының Волшебная ур., Чудесная ур., Счастливая ур., Добрая ур., Звездная ур., Удачная ур., Дружная ур., Любимая ур., , Ясная ур., Небесная ур., Сказочная ур., Живописная ур., Светлая ур., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
4. 2022 елның 29 окябренә 13.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авылында Удачная урамы буенча 18 йорт янында Кече Шилнә авылының Боровая ур., Кленовая ур., Широкая ур., Светлая ур., Вербная ур., Березовая ур., Травяная ур., Хвойная ур., Заповедная ур., Рощинская ур.буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Кече Шилнә авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.
6. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

««2023 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Кече Шилнә авылында юлларны ремонтлау;
2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;
3) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау
4) тротуарны төзекләндерү
5) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

9. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов